**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АНДРЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АНДРЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Андреевка ав. **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 2

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Андреевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 10 апрелендә 10 сәгать 00 минутка Ленин урамындагы "Яшьләр" балалар мәйданчыгында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә Гагарин урамы 1-8 санлы йортлардан, Зайкин урамы 2-17 санлы йортлардан, Ленин урамы 3-47/2 санлы йортлардан, Садовая урамы 1-27 санлы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2024 елның 10 апрелендә 11 сәгать 00 минутка К.Маркс урамындагы "Үзәк" балалар мәйданчыгында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә К.Маркс урамы буенча 5-35 санлы йортлардан, Н.И. Маслаков урамы буенча 1-48 нче йортлардан, Полевая урамы буенча 1-58 нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2024 елның 10 апрелендә 12 сәгать 00 минутка Н.И. Маслаков урамы 67нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегендә Буранов урамы буенча 2а-20 санлы йортлардан, К.Маркс урамы буенча 37-75нче йортлардан, Н.И. Маслаков урамы буенча 50-90 нчы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Андреевка авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билгеләнеш буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитет тарафыннан башкарыла.

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез элек расланган гражданнар җыеннарында чыгарылган сорауларга үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегенең Андреевка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 24 октябрендәге 1 номерлы карары,
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлегенең Андреевка торак пунктында гражданнар Җыенының 2023 елның 24 октябрендәге 2 номерлы карары,

аны түбәндәге редакциядә расларга:

«Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Андреевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

« РИЗА»  «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru , бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Андреевка авыл җирлеге башлыгы  Егорова Н.И.